ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШАРШАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШАРШАДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2026 Шаршады авылы № 2

2026 елга вафат булганнарны күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясен раслау турында

«Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы,«2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлегендә 2026 елда хатынына (иренә), якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкиленә яисә үз өстенә күмү бурычын алган башка затларны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлегендә үлгәннәрне күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2026 елга, ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкиле яисә башка затлары булмаган очракта, мәет җирләү бурычын үз өстенә алган гарантияләнгән исемлеге бәясе (2 нче кушымта)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе С.Л. Залетов

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районының Шаршады авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2026 елның 29 гыйнварындагы 2
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлегендә 2026 елда хатынына (иренә), якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкиленә яисә үз өстенә күмү бурычын алган башка затларны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| № п/п | Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләрнең бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4144,72 |
| 3. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 1017,25 |
| 4. | Күмү (кабер казу һәм күмү) | 4516,66 |
| | **Барлыгы** | **9678,63** |

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районының Шаршады авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2026 елның 29 гыйнварындагы 2
номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлегендә үлгәннәрне күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2026 елга, ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары, законлы вәкиле яисә башка затлары булмаган очракта, мәет җирләү бурычын үз өстенә алган гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| № п/п | Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләрнең бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Тәннең киеме | 745,47 |
| 3. | Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3735,40 |
| 4. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 916,34 |
| 5. | Күмү (кабер казу һәм күмү) | 4281,42. |
| | **Барлыгы** | **9678,63** |